**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2022 елның «12» маеннан № 150

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан РеспубликасыЯңа Чишмә муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортының җайга салынулы тарифлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатыннан ташучыларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018елның 08 ноябрендәге 527 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны җайга салу һәм идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының билгеләнгән чикләрендә транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне, юридик затларга, индивидуаль

эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карарына һәмТатарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2018 елның 08 ноябрендәге 527 номерлы карар белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә шәһәр яны автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга даими рәвештә тарифларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 нче кушымтаның 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Ташучы Башкарма комитет һәм (яки) муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидияләр бирүче тәртипләрнең һәм шартларның үтәлешен, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, тикшерүләр үткәрүгә ризалык белдерә.»;

7.1. пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«, шулай ук аларны бирүнең нәтиҗәләре.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында (http://novosheshminsk.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов